КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 13 август г.Казань № 808

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләре тәкъдиме буенча һөнәри белем алуга һәм башка җирлеккә өстәмә һөнәри белем алуга юнәлдерелүгә бәйле рәвештә эшсез гражданнарга финанс ярдәме күрсәтү кагыйдәләрен раслау турында» 2012 ел, 16 март, 228 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2022 елда халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүне оештыру үзенчәлекләре турында» 2022 елның 16 мартындагы 376 номерлы карарын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләре тәкъдиме буенча һөнәри белем алуга һәм башка җирлеккә өстәмә һөнәри белем алуга юнәлдерелүгә бәйле рәвештә эшсез гражданнарга финанс ярдәме күрсәтү кагыйдәләрен раслау турында» 2012 ел, 16 март, 228 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 2 февраль, 51 нче, 2017 ел, 6 декабрь, 938 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итү хезмәтенең дәүләт учреждениеләре тәкъдиме буенча» сүзләрен төшереп калдырырга;

1 пунктта «Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итү хезмәтенең дәүләт учреждениеләре тәкъдиме буенча» сүзләрен төшереп калдырырга;

2 пунктта «Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итү хезмәтенең дәүләт учреждениеләре тәкъдиме буенча» сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле $2^1$ һәм $2^2$ пунктлар өстәргә:

«2[1]. 2022 елда әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләре тәкъдиме буенча һөнәри белем алуга һәм башка җирлеккә өстәмә һөнәри белем алуга юнәлдерелүгә бәйле рәвештә эшсез гражданнарга финанс ярдәме күрсәтү кагыйдәләре шулай ук эштән азат ителү куркынычы булган затлар категориясенә караган туры килә торган эш эзләү максатларында теркәлгән гражданнарга (оешма ябылуга яисә шәхси эшкуар эшчәнлеген туктатуга, оешма, шәхси эшкуар хезмәткәрләре санын яисә штатын кыскартуга һәм алар белән хезмәт килешүләрен өзүгә бәйле рәвештә эштән азат ителүгә планлаштырылган гражданнар); эш бирүче инициативасы буенча тулы булмаган эш көне (смена) һәм (яисә) тулы булмаган эш атнасы режимына эшкә күчерелгән; гади карар кабул иткән эш бирүчеләр белән хезмәт мөнәсәбәтләрендә торучы; эш бирүчеләр белән хезмәт мөнәсәбәтләрендә булган, аларга карата бөлгенлек (банкротлык) турында процедуралар кулланылган; хезмәт хакы сакланмыйча ялда булган; эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче гражданнарга кагыла.

2[2]. Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итү хезмәтенең тиешле дәүләт учреждениесендә гражданны әлеге карарның 2[1] пунктында күрсәтелгән категориягә кертүне раслый торган документлар һәм (яисә) белешмәләр булмаганда, мондый документлар һәм (яисә) белешмәләр гражданнан йә аның эш бирүчесеннән соратып алына.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләре тәкъдиме буенча һөнәри белем алуга һәм башка җирлеккә өстәмә һөнәри белем алуга юнәлдерелүгә бәйле рәвештә эшсез гражданнарга финанс ярдәме күрсәтү кагыйдәләрендә:

исемендә «Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итү хезмәтенең дәүләт учреждениеләре тәкъдиме буенча» сүзләрен төшереп калдырырга;

1 пунктның беренче абзацында «дәүләт учреждениеләре тәкъдиме буенча» сүзләрен «дәүләт учреждениеләре» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктта «үзәкләр тәкъдиме буенча» сүзләрен «үзәкләр» сүзләренә алмаштырырга;

күрсәтелгән Кагыйдәләргә 1 нче кушымтаның нумерация исемендә «Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итү хезмәтенең дәүләт учреждениеләре тәкъдиме буенча» сүзләрен төшереп калдырырга;

күрсәтелгән Кагыйдәләргә 2 нче кушымтаның нумерация исемендә «Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итү хезмәтенең дәүләт учреждениеләре тәкъдиме буенча» сүзләрен төшереп калдырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин